**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

________ **№ 30**

«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Аккүз авыл җирлеге Советының «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Аккүз авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның 28 апрелендәге 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Аккүз авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү, аларның хезмәте өчен түләүне камилләштерү һәм һөнәри хезмәт эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт хакы турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның хезмәте, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, контроль-хисап органнары рәисләре, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 22 мартындагы ПУ-239 номерлы Указы нигезендә, Актаныш муниципаль районының Аккүз авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Аккүз авыл җирлеге Советының «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Аккүз авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның 28 апрелендәге 6 номерлы карарына, 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4. Әлеге карар “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында” басылып чykканнан соң үз көченә керә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Аккүз авыл җирлегенең Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, һәм 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.”.

2.Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Актаныш муниципаль районының Аккүз авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы И.А.Сәлихҗанов